**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Казма авылында гражданнар җыены карары**

18.11.2022 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегенең Казма авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Килдураз авыл җирлегенең Казма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Казма авылында хуҗалык ысулы белән юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм кышкы чорда юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) өчен юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Килдураз авыл җирлегенең Казма авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Килдураз авыл җирлеге башлыгы _________ З.З.Әхәтов

Гражданнар җыены секретаре _________ А.Н. Юнысова